БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» 03 2021 ел № 108

«Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210 – ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Балтач районы Прокуратурасының 2021 елның 22 гыйнварындагы 02-08-02-21 номерлы протестын карап, Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасында социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗларны исәпкә кую буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.6 пунктның 4 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 3.4.1. пунктның 2 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 3 нче кушымтаның 1 пунктындагы 4 абзацны төшереп калдырырга,
- 2.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 7 пунктча өстәргә:

«7) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булганда.».

2. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ

регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Чернобыль АЭСындагы аварияда, «Маяк» җитештерү берләшмәсендәге аврияда радиация йогынтысына дучар булган гражданнарны һәм аларга тиңләштерелгән затларны исәпкә кую һәм Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 2.6 пунктның 3 пунктчасын төшереп калдырырга.

3. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм мәҗбүри күченүчеләргә торак сатып алуга субсидияләр бүлеп бирүгә Дәүләт торак сертификаты бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (3 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.5 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 2.6 пунктның 3 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 1 нче кушымтаның 4 пунктын (гариза бланкын) төшереп калдырырга.

4. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган Социаль түләүләрдән файдаланып торак шартларын яхшыртырга теләк белдергән гражданнар исемлекләренә кертү һәм авыл җирендә торак төзелешенә (сатып алуга) социаль түләү бирү турында таныклык бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (4 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кетергә:

- 2.5 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 2.6 пунктның 2 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 3.4.1 пунктның 2 пунктчасын төшереп калдырырга,
- 1 нче кушымтаның 4 пунктын (гариза бланкын) төшереп калдырырга.

5. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган

муниципаль берәмлек чикләрендә тулысынча яисә өлешчә җирле әһәмияттәге юллар буйлап узучы маршрутлар буенча автомобильдә авыр йөкләрне, зур габаритлы йөкләрне ташуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (20 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1.4 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Автомобиль транспортында йөкләр ташу кагыйдәләрен раслау һәм Россия Федерациясе юл хәрәкәте кагыйдәләренең 2.1.1 пунктына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 21 декабрендәге 2200 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән (алга таба - 2200 номерлы карар)»

- 1.5 пунктның 2 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«авыр йөк ташый торган транспорт чарасы - йөк төягән яисә йөксез булган массасы транспорт чарасының рөхсәт ителгән массасыннан артып киткән һәм (яки) аның күчәренә йөкләнеше транспорт чараларына рөхсәт ителгән йөкләнештән артып киткән транспорт чарасы.»,

- 1.5 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Транспорт чарасының рөхсәт ителгән массасы яисә транспорт чарасы күчәренә йөкләнеше дигәндә, тиешенчә 2200 номерлы Карарының 2 нче кушымтасы нигезендә транспорт чарасы массасы яисә 2200 Карарның 3 нче кушымтасы нигезендә транспорт чарасы күчәренә йөкләнеш яки түбәндәге шартлар үтәлгәндә, әлеге автомобиль юлы хуҗасы тарафыннан аерым автомобиль юлына (автомобиль юлы участогына) карата билгеләнгән транспорт чарасы массасы яисә транспорт чарасы күчәренә йөкләнеш:»,

- 1.5 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«транспорт чарасы массасының күрсәтелгән күрсәткечләре 2200 номерлы карарның 2 нче кушымтасында каралган күрсәткечләрдән артып китә;»,

- 1.5 пунктның 5 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«транспорт чарасы күчәренә йөкләнешнең күрсәтелгән күрсәткечләре 2200 номерлы карарның 3 нче кушымтасында каралган күрсәткечләрдән артып китә;»,

- 1.5 пунктның 6 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«зур габаритлы транспорт чарасы - йөк төягән яисә йөксез габаритлары 2200 номерлы Карарның 1 нче кушымтасы нигезендә транспорт чарасының рөхсәт ителгән иң чик габаритларыннан артып киткән транспорт чарасы;».

6. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү турындагы административ регламентына (16 нчы кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.9 пунктына түбәндәге эчтәлекле 4 пунктча өстәргә:

«4) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булганда.».

7. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм торак – коммуналь хуҗалык бүлеге тарафыннан муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең актуальләштерелгән административ регламентларын раслау турында» 2019 елның 19 июлендәге 262 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карары (2020 елның 18 ноябрендәге 321 номерлы үзгәрешләр белән) белән расланган административ регламентларга түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 2.14 пунктны таблица нигезендә түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Таблица

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, гариза бирүчеләрнең көтү һәм аларны кабул итү урынына, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә инвалидларның күрсәтелгән объектлардан файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итүгә, әлеге хезмәтләрне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүматны урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә карата таләпләр | Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгын системасы һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционирлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.<br><br>Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиалы мәгълүмат Гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.<br><br>Бинаның, бүлмәләрнең һәм хезмәтләрнең инвалидлар, шул исәптән кресло-коляскалардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итү чаралары күрелә, шул исәптән:<br><br>бинага һәм бүлмәләргә тоткарлыксыз керү йөрү, шулай ук аларда күрсәтелә торган хезмәтләрдән файдалана алырлык булу өчен шартлар;<br><br>объектлар урнашкан территория буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, объектның бинасына һәм бүлмәләренә | Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары»;<br><br>210-ФЗ номерлы Федераль закон;<br><br>«Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 декабрендәге 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары |

| | | |
|---|---|---|
| | керү һәм чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляска файдаланып, утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге;<br><br>күрү функциясендә һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясендә тайпылышлары булган инвалидларны озата йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү; инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат чыганакларын тиешенчә урнаштыру;<br><br>инвалидларга кирәкле авазлы һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифты белән башкарылган билгеләр ярдәмендә кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче кертү;<br><br>«Озата йөрүче этнең махсус өйрәтелгән булуын раслаучы документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы белән расланган формада һәм тәртиптә озата йөрүче этне махсус укытуны раслаучы документ булганда, мондый этне бинага һәм бүлмәләргә кертү;<br><br>хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга күрсәтелә торган хезмәтләрне башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә алырга комачаулый торган каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү.<br><br>Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның | |

| | | |
|---|---|---|
| | файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң капиталь ремонт, реконструкция, модернизация үткән, файдалануга тапшырылган объектларга карата кулланыла | |

8. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет - ресурсында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына (территориаль үсеш буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе

А. Ф. Хәйретдинов